

Рузаевка районы Татар Пешлә мәдәният йортында балалар очен жәйге каникулллар буе торле-торле чаралар оештырып киләләр.
Аларга һаванын торле торышы да шатлык; бернинди комачаулыксыз vз эшләре белән шогыльләнәләр. Шулай, vткән атнада Татар Пешлә клубы һәм китапханә хезмәткәрләре vзешчән сәнгать осталары очен “Жәйге мавыктыргычлар” исемле кызыклы кичә vткәрделәр. Балалар “Минем жәй кәгазьдә” дигән рәсем конкурсында катнаштылар.
Татар Пешлә клубынын урам территориясендә яшь буын очен кvнел ачу һәм танып белv журналлары тәкъдим ителгән “Нинди яналыклар?” дигән библиоплощадкасы да эшләде. Бу актив кон азагында “Жәй ничек vтте” дигән темага әнгәмә корып бергәләп чәй дә эчеп утырдылар.
Ә олырак яшьтәге балалар очен биредә “Жәйнен ачык тосләре - Яркие краски лета” дигән мавыктыргыч программа тормышка ашты. Балалар, вакытларын кvнелле vткәрv очен, клуб янындагы уен мәйданына жыелдылар. Мәдәният хезмәткәрләре,  «Дорогою добра» дигән волонтерлар агымы әгъзалары белән бергә, клубтагы тvгәрәкләрдә катнашучылар очен торле-торле уеннар һәм конкурслар әзерләгән иделәр. Рәхәтләнеп катнаштылар. Хәтта явып vткән жәйге янгыр да аларга комачауламады!
Менә шулай матур vтә балаларнын жәйләре.
Әйтеп китәргә кирәк, бу авыл администрациясе дә матур эшләр башкара. Кvптән тvгел татар әдәбиятынын классик язучысы, якташыбыз Шәриф Камалнын истәлекле ташы тирәсен жыештырдылар, чәчәкләр утыртып су да сиптеләр.